| | |
|---|---|
| СОВЕТ МУРАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӨРӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 27 нче апреле Мөрәле авылы № 7

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Мөрәле авыл җирлеге Советының кайбер
карарларын юкка чыгару турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы, «Азык-төлек продуктларының сыйфаты һәм куркынычсызлыгы турында» һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 1 мартындагы 47-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм муниципаль хокукый актларны муниципаль хезмәт турындагы гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Кайбыч муниципаль районы Мөрәле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авылы җирлеге Советының:

- Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәтен алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 2017 елның 7 августындагы 14 номерлы;

- «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авылы җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрне бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 9 апрелендәге 4 номерлы;

- «Азык-төлек продуктларын сату һәм аларның әйләнешен гамәлгә ашыруга таләпләр һәм Мөрәле авыл җирлеге территориясендә базар, сәүдә пунктларының эш тәртибе турында» 2007 елның 26 июлендәге 29 номерлы;

- "Азык-төлек продуктларын сату һәм аларның әйләнешен гамәлгә ашыруга таләпләр тәртибенә һәм Мөрәле авыл җирлеге территориясендә

базар, сәүдә пунктлары эше кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 30 сентябрендәге 24 номерлы карарларын гамәлдән чыгарырга.

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырырга һәм Кайбыч муниципаль районының Мөрәле авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Мөрәлеавыл җирлеге
Башлыгы урынбасары Р.Р.Зиннәтуллин